СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2021 г. Заинск № 36

**Зәй муниципаль районы территориясендә җир эшләрен башкару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы территориясендә җир эшләрен башкару тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта).

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN. RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Советының 2021 елның
03 март
36 номерлы карарына
кушымта

**Зәй муниципаль районы территориясендә җир эшләрен башкару тәртибе турында**

## НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп эшләнгән.

1.2. Әлеге нигезләмәне Зәй муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бара торган барлык юридик һәм физик затларның (җир кишәрлекләренә милек, файдалану яисә арендалау хокукына бәйсез рәвештә) үтәве мәҗбүри:

а) биналарны, корылмаларны, җир асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләрен һәм коммуникацияләрне проектлау һәм төзү;

б) җир эшләре башкаруга проект документациясен килештерү;

в) җир эшләре башкаруга контроль һәм күзәтчелек.

1.3. Әлеге нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төп терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

а) **җир эшләре** - 30 сантиметрдан артык тирәнлектә грунт ачу, барлык төр объектларны һәм корылмаларны, җир асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләрен, коммуникацияләрне торгызганда субайлар кагу һәм батыру, шулай ук 50 сантиметрдан артык биеклектә туфрак тарату белән бәйле эшләр;

б) **җир эшләрен башкаруга ордер** - Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән күчемсез милек объектларын, җир асты инженерлык корылмаларын һәм коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда җир эшләре башкаруга, бораулауга һәм башка эшләр башкаруга хокук бирә торган документ;

в) **эшләр башкаручы** - җир эшләрен башкару хокукын соратып алучы физик яки юридик зат;

д) **авария хәле** - җирлек, квартал, торак йорт, башка тереклек өчен мөһим объектта инженерлык коммуникацияләре һәм корылмалар эшендә алдан фаразланмаган, көтелмәгән авария нәтиҗәсендә ресурслар белән тәэмин итүдә (су, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, юынтык суларны

чыгару) шактый өзеклекләр, тулысынча тукталу яки тәэмин итүнең ышанычлылыгы киму ситуациясе.

## 2. Җир эшләре башкаруга ордер бирү тәртибе

2.1. Исемлек нигезендә җир эшләренең барлык төрләрен башкару (1 нче кушымта) җир эшләрен башаруга ордер булган очракта гына (алга таба - ордер) рөхсәт ителә.

Зәй муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен төзекләндерү белән бәйле җир казу, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм уздыру, җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерү һәм алу җирле үзидарә органнарының хокукый актларында билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Төзелеш һәм җир эшләре, территорияне төзекләндерүгә бәйле инженерлык коммуникацияләрен төзү һәм ремонтлау эшләрен башкару срокларын килештерүне һәм координацияләүне Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра. Җир эшләрен башкаруга ордер вәкаләтле орган тарафыннан бирелә.

2.3. Заказчы яки эшләр башкаручы (алга таба – мөрәҗәгать итүче) ордер алу өчен вәкаләтле органга гариза (2 нче кушымта) һәм кирәкле документларны (3 нче кушымта) җибәрә.

Эшләрне башкаручы, заказчының рәсмиләштерелгән ордеры булуына инанмый торып, эш башкарырга хокуклы түгел.

Вәкаләтле орган җир эшләрен башкаруга ордер алу өчен гариза алынганнан соң 13 көн эчендә:

а) документлар булу һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

б) проектның дәүләт шәһәр төзелеше нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры килүен тикшерә;

в) җир эшләрен башкаруга ордер бирә яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, ордер бирүдән баш тарта.

Вәкаләтле орган әлеге тәртипнең 4 нче кушымтасында каралган очракларда ордер бирүдән баш тарта.

2.4. Ордер мөрәҗәгать итүчегә бирелә

2.5. Ордерны биргәндә вәкаләтле орган эшләрне башкару срокларын һәм бозылган территорияне кабат төзекләндерүнең вакытын билгели.

Ордер, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре белән каралган эшләрне башкаруның норматив дәвамлылыгын исәпкә алып, эшләрне башкаруның билгеләнгән графигы нигезендә, билгеле бер вакытка рәсмиләштерелә.

Ордер анда күрсәтелгән эш төрләре, күләме, вакыты һәм урыны өчен генә гамәлдә. Эшләр ордерда күрсәтелгән эшләрне башкаручы тарафыннан гына башкарыла ала. Эш башкару барышында гариза бирүче вәкаләтле органга рөхсәт бирү шартларын үзгәртү (эшләрне җаваплы башкаручы, лицензияләр срогы тәмамлану, проект карарларының сизелерлек үзгәрешләре һ. б.) турында хәбәр итә. Ордерда күрсәтелгән эшләр башкаручыны

алыштырган, объектны башка эш башкаручыга тапшырган очракта, заказчы ордерны башка эш башкаручыга яңадан рәсмиләштерергә тиеш. Гамәлдәге ордерга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү аны бирү урыны буенча гына башкарыла.

Ордерда күрсәтелгән эшләр башлану срогы 5 (биш) эш көненә тоткарланганда, бирелгән ордер гамәлдә түгел дип санала һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан, срок узганнан соң, 3 эш көне эчендә вәкаләтле органга кире кайтарылырга тиеш.

2.6. Җир эшләренең барлык төрләрен башкарганда, эш бер айдан артыкка сузылганда ордер аерым этапларга, аларның һәркайсына эш срокларын билгеләп, бирелә ала.

2.7. Вәкаләтле орган ордерның гамәлдә булуын түбәндәге очракларда туктатып тора:

- әгәр җир эшләре башкарыла торган объектның торышы кешеләр тормышына, сәламәтлегенә һәм транспорт хәрәкәтенә куркыныч тудырса;

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан ордерны рәсмиләштерүнең билгеләнгән тәртибен бозу очраклары ачыклану, ордер нигезендә бирелгән гамәлләрне, рөхсәтләрне, килешүләрне вакытлыча туктату;

- җир эшләре алып барыла торган урын белән янәшә урнашкан биналар һәм корылмаларның конструкцияләре һәм элементлары деформацияләнү.

Ордерның гамәлдә булуы туктатылган очракта, мөрәҗәгать итүчедән ордер алынырга тиеш.

Ордерның гамәлдә булуын туктатып торуга сәбәп булган җитешсезлекләрне бетергәннән соң, ул яңадан гамәлгә кертелә (ордер мөрәҗәгать итүчегә кире кайта). Шул ук вакытта ордерда аның гамәлдә булуын тиешле чорда туктатып тору турында билге ясала.

Ордерның гамәлдә булуын торгызу мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүе буенча башкарыла, ул хокук бозуларны бетерүне раслый һәм алга таба җир эшләрен башкарганда әлеге кагыйдәләрнең үтәлешен гарантияли.

2.8. Гамәлдә булу вакыты чыккан ордер буенча эшләр башкару тыела. Гамәлдә булу вакыты чыккан ордер буенча эшләр башкару җир эшләрен үз белдеге белән башкару дип танылa. Эшләрне билгеләнгән срокта үтәмәгәндә яки эшләрне ордерда билгеләнгән срокта тәмамларга мөмкинлек бирми торган сәбәпләр килеп чыккан очракта, мөрәҗәгать итүче ордер срогын озайту турында гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә тиеш. Ордерны озайту ордерда күрсәтелгән срок беткәнче биш календарь көннән дә ким булмаган вакыт эчендә башкарыла.

2.9. Финанслау булмау сәбәпле эшләр туктатылганда ордер, эшләр башкару хокукыннан башка (бары тик төзелеш мәйданчыгының коймаларын һәм территориясен карап тотуга гына), заказчыга яңадан рәсмиләштерелә һәм аңа төзелеш мәйданчыгын карап тоту өчен тулы җаваплылык бирелә.

Озак вакыт эшләр башкару финансланмаган очракта объектта эш туктатылып торырга, ордер ябылырга мөмкин. Ябылган объектны карап тоту өчен заказчы җаваплы.

2.10. Зур озынлыктагы трассаларда һәм автомобиль юллары кисешкән урыннарда эшләр башкарганда, ордер, һәр участокка эш вакытын билгеләп, һәр участок өчен аерым бирелә, ләкин буе 100 метрдан да артык булмаган суүткәргеч, канализация, җылылык трассасы, газүткәргечкә һәм буе 200 метрдан да артык булмаган телефон һәм электр кабельләре өчен һәм автомобиль юллары чатына.

### 3. Инженерлык-коммуникация эшләрен (җир), ремонт һәм башка эшләр башкару тәртибе

3.1. Киләсе елда җир асты челтәрләрен, корылмаларны төзү яки реконструкцияләү (подряд яки хуҗалык ысулы белән) буенча эшләр башкарырга тиешле оешмалар, төзелеш яки реконструкция өчен билгеләнгән трассаларның сызымнарын теркәп, киләсе елның 1 октябренә кадәр вәкаләтле органга планлы гаризалар тапшырырга тиеш.

3.2. Магистраль урамнарда, заманча өслекле юлларда һәм мәйданнарда җир асты коммуникацияләре салуның һәм аларны яңача төзүнең төп ысулы - төзек өслекне ачмый гына ябык ысул белән эш башкару.

Магистраль урамнарда, проспектларда, юлларда һәм заманча өслекле мәйданнарда инженерлык коммуникацияләрен салуның һәм яңача төзүнең ачык ысулы бары тик вәкаләтле орган тарафыннан язмача бирелгән рөхсәт кәгазе буенча гына мөмкин.

3.3. Автомобиль юлларының техника күп йөри торган өлешендә җир эшләре башкару, автотранспорт хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату (урамны ябу) таләп ителгәндә, бары тик юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге орган белән килештереп кенә башкарыла.

3.4. Җир эшләре башланыр алдыннан гариза бирүче җир эшләре башланганчыга кадәр бер тәүлектән дә соңга калмыйча, эшләр башкару урынына эксплуатация хезмәтләре һәм башка оешмалар, учреждение һәм физик затларны, җир асты корылмалары яисә башка объектлар булган вәкаләтле вәкилләрне чакыртырга тиеш. Бу тәртип шулай ук җир эшләре башкаруны килештерү кәгазендә оешма яки җир эшләре башкарылачак җир кишәрлегеннән файдаланучы физик затларны, шулай ук катнаш һәм параллель инженерлык челтәрләре, башка объектлар булган оешмаларны яки физик затларны чакырту зарурилыгы күрсәтелгәндә дә кулланыла.

3.5. Ордерда күрсәтелгән эксплуатацияләү һәм башка оешмалар җитәкчеләре үз вәкаләтле вәкилләренең эш урынына килүен тәэмин итәргә бурычлы. Бер үк вакытта җир асты корылмаларының, коммуникацияләрнең һәм башка мөлкәтнең сакланышын тәэмин итү һәм зыян килүне кисәтү максатыннан, эшләрне башкаруның аерым шартлары төгәлләштерелә һәм язмача теркәлә.

Проектта күрсәтелмәгән җир асты коммуникацияләре һәм корылмалары ачыкланган очракта, эшләр башкаруга комачауламаса да, җир эшләре башкару тыела. Җир казу урынына коммуникацияләр һәм корылмалар хуҗаларының вәкилләре чакырылырга тиеш. Бер үк вакытта

эшләрне башкаручы коммуникацияләрне һәм корылмаларны зарарланулардан саклау чаралары күрергә тиеш. Тиешле саклау чараларын тәэмин итү мөмкин булмаган очракта, эшләр әлеге коммуникацияләр һәм корылмаларның хуҗалары белән эшләрнең проектын килештергәнче туктатылырга тиеш.

3.6. Җир эшләрен башлаганчы, эш башкаручы, эш башкарыла торган урынны тиешле койма белән, санитария нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры китереп, әйләндереп ала һәм коймада эш башкаручы оешманың исемен, эшләрне башкару өчен җаваплы затның исемен, телефон номерын күрсәтеп, ГОСТ нигезендә типик юл билгеләре белән җиһазландыра.

Кичке һәм төнге сәгатьләрдә коймаларда Россия Федерациясе юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган яктылыкны кире кайтаручы кисәтү билгеләре булырга тиеш.

Техника хәрәкәтен ябу таләп ителгән юлларда казу эшләре башкарылганда, урында юл билгеләре урнаштырыла, РФ ЭЭМ органнарында расланган схемалар буенча әйләнеп үтү юнәлеше күрсәтелә. Караңгылык башлану белән казу эшләре башкарылган урыннар яктыртып куела.

3.7. Эшләр башкарган вакытта җир эшләрен башкаруга җаваплы зат даими төстә җир казу эшләре барган урында булырга, аның үзе белән җир эшләре башкаруга ордер, билгеләнгән тәртиптә килештерелгән техник проект, РФ Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге белән килештерелгән юл хәрәкәте схемасы, эшләрне башкару проекты, шулай ук җир асты корылмалары һәм коммуникацияләр хуҗаларының күрсәтмәләре булырга тиеш.

3.8. Җир асты корылмаларын һәм коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда һәм яңача итеп үзгәрткәндә җир эшләре барган урыннарны коймалау чикләре эшләр башкару проектында билгеләнә. Төзелеш материаллары, техника һәм механизмнар коймаланган участок чикләрендә булырга тиеш. Җир эшләре урыныннан коймалар юл өслеген тулысынча торгызганнан соң гына алынырга тиеш.

3.9. Гамәлдәге җир асты инженерлык челтәрләренең, яшел утыртмаларның сакланышы өчен гариза бирүче җавап бирә. Янәшә яки кисешүче коммуникацияләргә зыян килгән очракта, алар әлеге коммуникацияләрне эксплуатацияләүче оешма күрсәтмәсе буенча эш башкаручы оешма көчләре һәм чаралары белән кичекмәстән торгызылырга тиеш.

Шәһәрнең үзәк урамнарында һәм мәйданнарында, транспорт һәм җәяүлеләрнең интенсив хәрәкәте урыннарында җир асты коммуникацияләрен төзү һәм реконструкцияләү эшләре (планнан тыш характердагылардан тыш) төнге вакытта башкарылырга тиеш. Коймалар, грунт һәм материаллар иртәнге сәгать 7гә кадәр алына һәм җыештырып куела.

3.10. Казып алына торган балчык коймаланган чикләрдән чыгарылмый. Көйләнмәгән территорияләрдә эш башкарганда, траншеяның бер ягына, кире күмү өчен, балчыкны өю рөхсәт ителә.

Сүтелгән юл өслекләре материаллары һәм төзелеш материаллары коймаланган урынның эчке ягында яки махсус билгеләнгән урыннарда өеп куелырга тиеш. Бордюр сүтелә, кәсле җир кагыла һәм аларның икенче кат куллануга яраклылыгы билгеләнә. Эшләрне башкаручы шулай ук сүтелгән юл һәм тротуар өслекләренең, борт ташының, баскычларның һәм түшәм плитәләренең сакланышын тәэмин итәргә бурычлы.

Җир эшләрен башкарганда грунт, төзелеш материаллары, сүтелгән юл өслекләренең материалларын урамнарның машиналар йөри торган өлешендә, тротуарларда, тәртипкә салынган газоннарда өеп кую тыела.

3.11. Транспорт магистральләренең, юлларның һәм урамнарның үтеп йөри торган өлешендә, җәяүлеләр тротуарларында һәм башка төзекләндерелгән территорияләрдә, газоннарда җир эшләре башкарганда траншея һәм грунт чикләрендәге каты өслек бары тик экология һәм табигать ресурслары буенча махсус вәкаләтле орган тарафыннан күрсәтелгән урыннарда гына казыла һәм эшкәртелә.

Юл өлеше һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ачу проект буенча каралган һәм рөхсәт ителгән ачыла торган траншея чикләрендә һәм күләмнәрендә башкарыла. Кискәләнгән асфальт өслек (скол) бер эш көне дәвамында чыгарылырга тиеш. Куптарылган асфальт кисәкләрен 2 тәүлектән артыкка өеп куярга рөхсәт ителми.

3.12. Заманча өслекле урамнарда, юлларда, тротуарларда, мәйданнарда һәм башка төзекләндерелгән территорияләрдә җир эшләре башкару түбәндәге шартларны үтәп алып барыла:

- казу эшләре эшләрне башкару проекты нигезендә кыска участоклар белән алып барылырга тиеш;

- алдагы участокларда эшләр, әлеге участокта эш тәгәлләнгәннән соң, шул исәптән, торгызу эшләре һәм территорияне җыештыру эшләре тәмамланганнан соң гына рөхсәт ителә;

- траншеяларның киңлеге, корылмаларның тышкы габаритларын исәпкә алып, мәмкин кадәр минималь булырга тиеш;

- траншеялар һәм котлованнар бөтен тирәнлекләренә ныгытылырга яки җир эшләрен башкаруга гамәлдәге кагыйдәләр нигезендә янтүшәмәләре булырга тиеш.

3.13. Җир эшләре үткәрелгән урыннарда һәм алар тирәсендәге территорияләрдә яңгыр һәм эрегән кар суларын агызуны эшләр башкаручы оешма тәэмин итәргә тиеш. Коеларны, яңгыр рәшәткәләрен һәм лотокларны саклау өчен коеларга, яңгыр суларына һәм лотокларга керү мөмкинлеген тәэмин итүче агач щитлар һәм тартмалар куллану зарур.

3.14. Гамәлдәге инженерлык коммуникацияләренә һәм алар белән кисешкән урыннарга турыдан-туры якын җирдә җир эшләре башкару тиешле санитар нормалар һәм кагыйдәләр, эшләр башкару кагыйдәләре һәм эксплуатация оешмаларының норматив документлары таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән эшләр башкаручы, шулай ук эксплуатацияләүче хезмәтләр хуҗалары күзәтүендә башкарыла, алар урында грунтны кулдан казу чикләрен билгелиләр. Эшләп торган җир асты

коммуникацияләре һәм корылмалары янында, әлеге җир асты коммуникацияләре һәм корылмалары хуҗалары белән килештермичә, җир казу механизмнарын, бәрмә инструментларны (ломнар, кәйләләр, чөйләр, пневматик инструментлар һ.б.) куллану, эшләрне оештыру проектында каралмаган аралыкта экскаваторлардан файдалану тыела. Мондый очракларда эш кулдан гына башкарыла.

Җир эшләрен алып барганда туң һәм каты грунтларда ава торган савыл җайланмаларны газүткәргечләргә, терәк торбаүткәргечләргә, электр кабельләренә һәм башка җир асты коммуникацияләренә 5 метрдан да якынрак, объектларга 3 метрдан да якынрак арада куллану тыела. Ава торган савыл җайланмаларны торакка якын урында куллану тыела.

Гамәлдәге җир асты корылмаларына зыян китергән өчен җир эшләрен башкаручы оешмалар һәм физик затлар, шулай ук әлеге эшләрне объектта башкару өчен җаваплы вазифаи затлар җаваплылык тота.

3.15. Эшләр башкарганда тыела:

- РФ Эчке эшләр министрлыгы бүлеге белән килештермичә юлларда эшләр башкару;

- урамнарның якын-тирә участокларын һәм яңгыр канализациясен чүпләү;

- сүүткәргеч торбалар, кюветлар һәм газоннар күмү;

- газ үткәргечләрнең, җылылык трассаларының, электр тапшыру линияләренең һәм элемтә линияләренең саклана торган зоналарында материаллар һәм конструкцияләрне өеп кую;

- люк капкачларын, күзәтү коеларын һәм камераларын, су кабул итү коеларын, юл буе лотокларын һәм кюветларын, яңадан җибәрү торбаларын һәм дренажларны, геодезия билгеләрен, юл йөрү өлешен һәм тротуарларны, җир эшләре башкару өчен бүлеп бирелмәгән юлларны һәм тротуарларны туфрак яки төзелеш материаллары белән каплау, тутыру;

- траншеялардан, котлованнардан, коелардан суыртылган суны юлларга, тротуарларга һәм төзекләндерелгән территорияләргә агызу. Су шул участоктагы яңгыр канализациясенә яки шланг ярдәмендә һәм лотокларга агызылырга тиеш;

- гамәлдәге җир асты корылмаларын, расланган проектта каралмаган булса да, эшкә мөнәсәбәтле оешма һәм вәкаләтле орган белән килештермичә, әгәр дә әлеге корылма эш башкаруга комачауламаса да, күчерү;

- гамәлдәге җир асты челтәрләре трассаларында нинди дә булса корылмаларны һәм җиһазларны күчерү;

- яшел үсентеләрне кисү һәм күчерү, законда билгеләнгән тәртиптә күчерүгә рөхсәт бирмичә, тамыр системасын ачу;

- торак пунктлар урамнары буйлап транспорт һәм чылбырлы машиналарны куу;

- җир асты коммуникацияләренең чыгу юлы булмаган, геодезия хезмәте тарафыннан контроль-башкару төшерү эшләре башкарылганчыга кадәр салынган траншеяларны (кабель, торбалар салу өчен) күмү;

- вәкаләтле органда килештерелгән башкарма схеманы үтәмичә, төзелеш объектларын, инженерлык җир асты коммуникацияләрен файдалануга кабул итү һәм ордерны ябу.

3.16. Агач утыртылган территориядә җир эшләре башкарганда оешма, предприятиеләр, учреждениеләр яки физик затлар түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

- яшелләндерелгән территориядән файдаланучылар һәм вәкаләтле орган белән яшел утыртмалар зонасында төзелеш эшләре башлануын килештерергә һәм эшләрнең тәмамлануы турында ике көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

- газоннарга төзелеш материаллары өеп куймаска, машиналар кую урыннары ясамаска, шулай ук агачтан 2,5 м һәм куаклардан 1,5 м ераклыкта да. Яна торган материаллар агач һәм куаклардан 10 метрдан да ким булмаган ераклыкта өеп куела;

- яшел утыртмаларны төзелеш материаллары белән пычратмаска, калдыкларны агызмаска;

- күтәрү краннары килү юлларын һәм аларны урнаштыру урыннарын үсентеләрдән читтә урнаштырырга һәм агачларның коймаларын бозмаска;

- агачларның һәм куакларның тамыр системасы зонасында эшләрне тамыр системасына зыян китермичә төп скелет тамырлардан түбәнрәк башкарырга;

- җир эшләрен башкарганда җирнең өске уңдырышлы катламын кырып алу, буртлау һәм саклау, аны билгеләнгән урыннарга чыгаруны тәэмин итәргә, алга таба табигатьне саклау чараларын үткәрү һәм бозылган җирләрне торгызу өчен;

- төзелеш территориясендәге агачларны 2 м биеклектәге тоташ шитлар белән киртәләргә. Щитларны агачтан кимендә 0,5 м ераклыкта өчпочмак итеп урнаштырырга, шулай ук киртәли торган өчпочмак тирәли 0,5 м радиуслы агач түшәмә җәяргә;

- шәһәр юлларына, мәйданнарга, ишегалларына, тротуарларга һ.б.га таш җәйгәндә һәм асфальт салганда, агач тирәсендә, тимер-бетон рәшәткә яисә башка өслек урнаштыруны исәпкә алып, диаметры 2 метрдан да ким булмаган ирекле пространство калдырырга;

- кабель сузганда, канализация торбалары һәм башка корылмалар салганда траншеяларны казуны агач кәүсәсеннән агач кәүсәсенең калынлыгы 15 см. га кадәр булганда, 2 метрдан да ким булмаган арада, кәүсәнең калынлыгы 15 см. дан артык булганда, 3 метрдан да ким булмаган арада, куаклардан - 1,5 м. дан да ким булмаган арада, агач кәүсәсеннән алып, һәр скелет тармагы нигезеннән ераклыкны исәпләп, башкарырга кирәк.

- гамәлдәге утыртмалар районында юлларны, тротуарларны һәм башка корылмаларны реконструкцияләгәндә һәм төзегәндә, аларны төшергәндә яки күтәргәндә, вертикаль тамгаларның гамәлдә булганнарына карата 5 см га үзгәрешләренә юл куймаска. Тамыр системасын күмү яки ачу котылгысыз очракларда, проектларда һәм сметаларда агач үсешенең нормаль шартларын саклау өчен тиешле җайланмалар куллану күздә тотыла;

- төзелеш эшләрен башкарганда, грунтны вәкаләтле орган күрсәткән урыннарга чыгаруны, табигатьне саклау чаралары үткәрүне һәм бозылган җирләрне яңадан торгызуны тәэмин итәргә.

## 4. Авария эшләрен башкару һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү тәртибе

4.1. Аварияләрне ликвидацияләгәндә (авария телефонограммасы буенча) инженерлык челтәрләрендә казу эшләрен авария хезмәтләренә ордерны, алдан рәсмиләштермичә, бер тәүлек эчендә рәсмиләштерү шарты белән эш башкарырга рөхсәт ителә.

4.2. Җир асты корылмаларында, инженерлык коммуникацияләрендә аларны эксплуатацияләү барышында авария хәле туганда яки төзелеш эшләре алып барылганда, аларның нормаль эшләве бозылу яки бәхетсезлек очраклары килеп чыгардай алшартлар барлыкка килү белән бәйле рәвештә, күрсәтелгән инженерлык корылмаларын һәм коммуникацияләрне эксплуатацияләүче оешма аварияне бетерү өчен кичекмәстән авария бригадасын җибәрергә тиеш, үзе белән хезмәт таныклыгы һәм авария хезмәтенең наряды, аварияне бетерүгә гариза яки авария турында телефонограмманың күчермәсе булган җаваплы зат җитәкчелегендәге бригада аварияне һәм аның нәтиҗәләрен бетерүгә керешергә тиеш. Авария эшләре аны тулысынча бетергәнчегә кадәр өзлексез режимда алып барыла.

4.3. Казу эшләре башланганчы, авария бригадасын җибәрү белән бер үк вакытта, эксплуатацияләүче оешма авария турында, эшләрне үткәрү урыны турында, җаваплы затларның шәхси мәгълүматлары турында вәкаләтле органга хәбәр итәргә, шулай ук телефонограмма бирү юлы белән инженерлык корылмаларыннан файдаланучы оешмага, РФ Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә (юлны чикләү яки ябу кирәк булганда) авария турында хәбәр җиткерергә, яшелләндерелгән территориядә аварияле эшләр башкарганда вәкаләтле органга хәбәр итәргә тиеш.

Җир эшләре башкарганда, янәшәдә урнашкан челтәрләрнең сакланышын тәэмин итү өчен, эшләр башкаручы әлеге урында җир асты коммуникацияләре булган эксплуатацияләүче оешмалар вәкилләрен чакыртырга тиеш.

Авария турында хәбәр алганнан соң, авария урыны белән чиктәш инженерлык коммуникацияләре һәм җир асты корылмалары булган оешма җитәкчеләре җаваплы вәкилләрнең авария урынына вакытында килүләрен тәэмин итәргә һәм әлеге коммуникацияләрнең һәм корылмаларның сакланышын тәэмин итү өчен мөһим шартлар үтәлеше турында язмача тулы күрсәтмәләр бирергә тиеш.

4.4. Авария хәлендә җир казуга рөхсәт (ордер) эшләрне башлау белән беррәттән рәсмиләштерелә. Әгәр авария эш көне булмаган вакытта яки ял көнендә килеп чыкканса, рөхсәт икенче көнне рәсмиләштерелә.

Эшләрне башкаручы оешма аварияне вакытында туктатмаган һәм территорияне төзекләндермәгән өчен, шулай ук ордерны рәсмиләштермәгәндә гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

4.5. Инженерлык коммуникацияләрендә аварияләрне бетерү эшләренең озынлыгы җәйге чорда өч тәүлектән дә, кышкы чорда биш тәүлектән дә артмаска тиеш.

4.6. Эшләр башкару өчен җаваплылар кешеләрнең куркынычсызлыгын һәм транспорт хәрәкәте иминлеген, янәшәдәге җир асты һәм җир өсте корылмаларының сакланышын, коймалар, юл билгеләре, күрсәткечләр, яктырткычлар, мәгълүмат щитларының булуын, аларның тиешенчә карап торылуын тәэмин итәргә тиеш; кирәк булган очракта, эшләр турында халыкка һәм җитештерү предприятиеләренә массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр ителә.

4.7. Җир асты коммуникацияләрендә аварияләрне бетергәннән соң юлларны, тротуарларны торгызу, әлеге нигезләмәнең 4.11 пунктында каралган очраклардан тыш, эшләр тәмамланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча башкарыла. Бу чорда җир казылган урыннарда урамнарның һәм тротуарларның машиналар йөрү өлешен карап тоту җир казу эшләрен башкаручы оешмага, предприятиегә, учреждениегә, өслекне ачучы физик затка йөкләнә. Эш алып барылган урында территорияне төзекләндерү эшләре тулы күләмдә территориянең беренчел торышына туры китереп башкарыла.

4.8. Авария-торгызу эшләре үткәрелгән объект территорияне төзекләндерү һәм юл-ремонт эшләренең фактта башкарылуын һәм аларның сыйфатын тикшергәннән соң, эшләрне башкаручы оешма вәкилләре, территория хуҗасы, вәкаләтле орган, шулай ук РФ Эчке эшләр министрлыгы бүлеге вәкилләре катнашында (әгәр эшләр машиналар йөри торган өлештә башкарылган булса) контрольдән төшерелә.

4.9. Авария хәлендә дигән сылтау белән планлы эшләр башкару тыела. Мондый юл белән эшләр башкаручы гаеплеләр гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

4.10. Авария булган инженерлык челтәрләренең хуҗалары өч ел дәвамында территорияне төзекләндерүнең торышы өчен җаваплылык тоталар.

4.11. Гамәлдәге җир асты корылмаларына һәм коммуникацияләренә зыян китергән өчен эшләрне башкаручы оешмалар һәм аларны башкару өчен җаваплы зат җавап бирә.

### 5. Җир эшләрен башкарганнан соң яңадан торгызу, төзәтү эшләре

5.1. Җир эшләре башкаручы оешма, предприятие, учреждение, физик зат, шәхси эшмәкәр бозылган газоннарны, яшел үсентеләрне, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, кече архитектура формаларын, борт ташын һәм юл йөрү өлешенең яки тротуарның бөтен киңлеген сыйфатлы итеп торгызырга тиеш.

5.2. Урамнарда, тротуарларда һәм мәйданнарда траншеялар һәм котлованнарны күмү вәкаләтле орган вәкиленең техник контроле астында башкарыла. Гамәлдәге коммуникацияләр белән кисешкән урыннарда траншеяларны күмү әлеге җир асты коммуникацияләреннән файдаланучы оешма вәкилләре катнашында башкарыла. Эшләр башкару өчен җаваплы зат траншея һәм котлованнарны күмә башлау вакыты турында вәкаләтле органга һәм тиешле оешмаларга үз вакытында хәбәр итәргә тиеш.

5.3. Әгәр ачу камилләштерелгән катламда башкарылган булса, траншея һәм котлованнны күмү ком-ташлы ком катнашмасын катламлап салып, каток белән тыгызлау юлы белән башкарыла һәм аннан соң су сибеп торылырга тиеш.

5.4. Күмүнең сыйфаты һәм материалларны тыгызлау дәрәҗәсе турында төзекләндерү эшен контрольдә тотучы вәкаләтле вазыйфаи затлар акт төзиләр. Траншеяларны кондицияләнмәгән туфрак белән күмгәндә, туфрак тиешле дәрәҗәдә тыгызланмаса яки башка технологик нормаларны бозып салынса, күмүнең сыйфатына техник контроль ясаучы зат эшне туктатырга, акт төзергә һәм аны административ хокук бозу турында беркетмә төзергә вәкаләтле затларга тапшырырга хокуклы.

5.5. Урамнарның һәм тротуарларның машиналар йөри торган өлешендә кабат күмү эше ком ярдәмендә катламлап тыгызлау (су сибеп тыгызлау), кышкы вакытта эрегән ком белән күмү юлы белән башкарыла. Яшел зонаны (газоннарны) яңадан торгызу (кабат күмү), өске катламны бары тик үсемлекләр үсә торган туфрак белән белән каплау юлы тогызылуны исәпкә алып башкарылырга тиеш. Туфрак калынлыгы 30 сантиметрдан да ким булырга тиеш түгел. Казылган урын тәртипкә китерелгәннән соң, туфракка газон үләне орлыгы чәчелә.

5.6. Траншеяларны, башкарма рәсемгә төшерми торып, күмәргә рөхсәт ителми.

5.7. Урамнарның машиналар йөри торган өлеше, юллар, шулай ук тротуарларда эшләр башкарганда, капламаларны торгызу туры линияләр буенча, юллар һәм тротуарларларның параллель һәм перпендикуляр кучәре буенча, бораулау җиһазы белән ачканда, юллар буенча траншеядан ике якка да 20 шәр сантиметрга капламның зарарланмаган өлешен кертеп һәм тротуарлар буенча - 15 сантиметр һәм экскаватор белән ачканда 20 һәм 15 сантиметрдан да ким булмаган озынлыкта башкарыла. Шул ук вакытта иске асфальт-бетон өслек киселә, чистартыла, вертикаль стеналар һәм нигез өслеге сумала (битум) белән эшкәртелә.

5.8. Грунтны, материалларны, конструкцияләрне, төзелеш чүп-чарын һәм коймаларны торгызу эшләреннән соң җыю мәҗбүри.

5.9. Юл өслекләрен торгызу өчен түбәндәге сроклар билгеләнә:

- магистральләрдә, скверларда, паркларда, җәяүлеләр өчен юлларда, шулай ук транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте көчле булган урыннарда, торгызу, төзекләндерү эшләре төзелеш оешмасы траншеяләрны күмгәннән соң кичектермичә башланырга тиеш;

- калган очракларда - траншеяны күмгәннән соң 2 тәүлектән дә артык түгел.

5.10. Юл катламының йөри торган өлешендә торгызу эшләре ел әйләнәсендә башкарыла. Эшләрне көзге-кышкы чорда (IV - I кварталда) башкарганда, эшләрне башкаручы зыян килгән урынны кар һәм боздан тулысынча чистартырга һәм юл өслегенең тиешле катламын торгызырга һәм кышкы чорда аның торышын даими күзәтеп торырга; җылы чорда, ләкин 25 апрельдән дә иртәрәк түгел, асфальт-бетон өслекне торгызырга тиеш. Асфальт-бетон өслекләрне торгызуның технологик эзлеклелеге - тышкы һава температурасы көзен - +10°Cта, ә язын + 5 °Cта башкарылырга тиеш. Асфальт-бетон өслекләрне торгызу мөмкин булмаган очракта, аларны тимер-бетон плитәләрдән җыелган өслекләргә алыштыру рөхсәт ителә.

5.11. Көзге-кышкы чорда (IV – I кварталлар) тотрыклы салкын тискәре температура торганда, бозылган төзеклекне торгызу, эш башкару мөмкинлеге булмау сәбәпле, вакытлыча схема буенча алып барыла һәм киләсе елның 1 июненә кадәр бозылган урыннар тулысынча үз хәленә кайтарылырга тиеш, ә ордерның гамәлдә булуы гарантия хаты һәм торгызу эшләре графигы нигезендә озайтыла.

5.12. Казылган урыннар сыйфатсыз итеп күмелгәндә, капламалар утырган, деформацияләнгән урыннар ачыкланган очракта, җир эшләрен башкарган оешмалар кабат төзәтүне өч ел буе үз өсләрендә калдыра, алар дефектларны үз исәпләренә кичекмәстән бетерергә яки эш башкару өчен подрядчы оешмага акча күчерергә, эшне башкарганнан соң тапшырырга бурычлы.

5.13. Җир асты коммуникацияләре һәм корылмалары хуҗалары күзәтү коеларының һәм яңгыр суларын кабул итү коеларының люкларын (капкачларын) юл өслекләре биеклегендә урнаштырырга һәм карап тотарга тиеш. Люк биеклеге СНиПта билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә, тиешле органнарның беренче таләбе буенча төзәтү эшләре 48 сәгать эчендә башкарылырга тиеш. Күзәтү һәм яңгыр суларын кабул итү коеларының һәм камераларның люклары ачык, җимерелгән булу рөхсәт ителми. Аларны алмаштыру тиешле органнар таләбе буенча 2 сәгать эчендә башкарылырга тиеш.

Җир асты коммуникацияләре һәм корылмалары хуҗалары күзәтү коесын ремонтлаганда аның конструктив элементларын гына төзәтеп калмыйча, аңа тоташкан асфальт өслекне дә тышкы люктан 20 сантиметр радиуста карап тотарга тиеш.

5.14. Төзекләндерү (юл өслеге, яшел утыртмалар һ.б.) буенча эшләрне үз көчләре белән башкару мөмкин булмаганда, оешма, предприятие, юридик һәм физик затлар, әлеге эшләрне башкару өчен махсуслаштырылган оешмалар белән килешү төзергә тиеш. Бу очракта төзелгән килешү эшләрне башкаруга ордерны рәсмиләштергән вакытта вәкаләтле органга тапшырыла.

Килешү төзү җир эшләрен башкаручы оешмадан төзекләндерү элементларын кабат үз хәленә кайтаруда җаваплылыкны төшерми.

Объектлар төзегәндә төзекләндерү элементларын (яшел зоналар, тротуарлар, борт ташлары) саклап калу мөмкин булмаган очракта, төзелешнең заказчысы аны үз исәбенә башкара.

5.15. Оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр, юридик һәм физик затлар тарафыннан башкарылган эш квартал эчендәге, ишегалды һәм башка территорияләрдәге урамнар, тротуарлар, җәяүлеләр юллары, газоннар, тулысынча төзекләндерелгәннән соң гына төгәлләнгән дип санала.

5.16. Эшләр һәм төзекләндерү тәмамланганнан соң, заказчы подрядчы оешма белән бергә вәкаләтле орган вәкилләренә, территория хуҗаларына кабат үз хәленә кайтарылган юл өслекләре, газоннар һәм төзекләндерүнең башка элементларын тапшыра. Эшләр тәмамланган дата булып юлларны төзекләндерү, газоннарны һәм өслекләрне торгызу турында актка кул кую датасы санала.

5.17. Урамнарда һәм мәйданнарда җир эшләре башкарылганда әлеге кагыйдәләрнең бозылуы, ордерда күрсәтелгән шартлар үтәлмәве, траншеялар сыйфатсыз күмелгән, юл өслекләре һәм яшел утыртмалар сыйфатсыз яңартылган, үз белдеге белән җир казылган яки башка хокук бозулар ачыкланган (техник проект, эшләр башкару проекты) очракта, казу эшләрен тикшереп торучы органнар, контрольлек итүче зат эшләрне туктатырга һәм законда каралган тәртиптә гаеплеләрне җаваплылыкка тарту өчен вәкаләтле органга тәкъдим җибәрергә хокуклы.

## 6. Гамәлгә яраксыз җир асты корылмаларын ликвидацияләү

6.1. Әгәр җир асты корылмасы тузган яки башка корылма белән алыштырылган булса, ул челтәрдән өзелеп, балчык астыннан алынырга һәм акт белән рәсмиләштерелергә тиеш.

Гамәлдә булмаган җир асты корылмаларын балчык астыннан алу эшләренең чыгымнары зур булганда, алар, түбәндәге шартларны мәҗбүри үтәп, җир астында калдырылырга мөмкин:

1) коелар 1 метрдан да ким булмаган биеклектә сүтелергә һәм тыгызлап ком белән күмелергә, ә капкачлар, рәшәткәләр һәм башка җиһазлар алынган булырга тиеш;

2) 300 мм диаметрлы торбаүткәргечләрдә һәм аннан югарырак коеларда һәм камераларда керү һәм чыгу тишекләре тыгыз итеп томалап куелырга тиеш;

3) зур үлчәмдәге кирпеч һәм бетон җир асты корылмалары таш материаллар белән яки ком белән томалап куела;

4) газүткәргечләр челтәрдән өзелә һәм өрдерелә;

5) электр кабельләре кыскартылырга тиеш.

6.2. Санап кителгән барлык чаралар да әлеге корылмаларның башкарма сызымнарында күрсәтелә һәм алар акт белән бергә вәкаләтле органга тапшырыла.

## 7. Ордерны ябу тәртибе

7.1. Эшләр тәмамланганнан соң, җир эшләрен башкаруга ордер алган оешма, предприятие, учреждение, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

1) ордерны ачканда ордер килештерелгән эшкә мөнәсәбәтле оешмалар тамгалары белән, җир эшләре башкаруга ордерның оригиналы;

2) юлларны һәм тротуарларның төзекләндерелүе һәм юл түшәмәләренең тулысынча торгызылуы турында гарантияле хат;

3) объектны файдалануга кабул итү турында дәүләт комиссиясе акты (яңа төзелеш, реконструкция);

4) бозылган урыннар торгызылганнан соң, эш урыныннан фоторәсемнәр;

6) вәкаләтле орган белән килештерелгән яңа салынган һәм реконструкцияләнгән инженерлык челтәрләре һәм объектларның рәсемгә төшерелүе (съемка), электрон рәвештә.

7) калдыклар барлыкка килгәндә, калдыкларны махсус оешмаларга тапшыру актлары;

8) яшел үсентеләрне кискәндә, күчереп утыртканда яки аларга зыян салганда – компенсацияли торган яшелләндерү буенча башкарылган эшләр актлары, яшел утыртмаларның тернәкләнеп китү актлары. Компенсацияли торган яшелләндерү үткәрелмәгән очракта, яшел үсентеләрне кискән өчен акчалата компенсацияне раслаучы түләү документлары;

9) рөхсәттә күрсәтелгән шартларны һәм срокларны үтәү.

7.2. Башкарылган эшләрне һәм төзекләндерү эшләрен кабул итү акт белән рәсмиләштерелә, ул контрольлек итүче органнар: вәкаләтле орган, территория хуҗасы, РФ МФД бүлеге (машиналар йөрү өлешендә һәм тротуарда эшләр башкарганда) һәм эш башкаручы вәкиле тарафыннан имзалана.

7.3. Эш башкару урынына чыгып тикшергәннән соң, теркәү кенәгәсендә ордерны ябу турында билге куела. Документлар белән ордер архивта ике ел дәвамында саклана.

## 8. Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

8.1. Әлеге нигезләмә таләпләрен бозган юридик затлар, гражданнар һәм вазыйфаи затлар, кемгә буйсынуына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык тоталар.

8.2. Ордерсыз яисә билгеләнгән срокларны бозып җир эшләрен башкару үз белдеге белән башкарылган булып тора һәм административ җаваплылыкка китерә.

8.3. Юл өслегең тәртипкә китерү, территорияне төзекләндерү һәм җир эшләрен башкару срокларын саклау өлешендә хокук бозуларга юл куйган вазыйфаи затлар һәм гражданнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

8.4. Әлеге нигезләмәне тупас бозу факты ачыкланган очракта, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, авыл җирлекләре хуҗалыгына шактый зур

матди зыян китергән предприятие яки оешмаларның вазыйфаи затларына материаллар хокук саклау органнарына законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

1 кушымта

**Эш башлар алдыннан ордер алырга кирәк булган**

**эшләрнең исемлеге**

1. Төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт.

1.1. Җир асты инженерлык челтәрләре:

- торба белән эшләнгән сүүткәргечләр, канализация, җылылык челтәрләре, нефть үткәргечләр һәм газүткәргечләр, яңгыр канализациясе, дренаж;

- кабель ярдәмендә үткәрелгән электр челтәрләре, элемтә челтәрләре, радио, телевидение, светофорлар, урам утлары.

1.2. Юллар, урамнарның машиналар йөрү өлеше, тротуарлар, борт ташы, бүлү полосалары, терәк диварлар, газоннар, электр линияләре терәкләре, тышкы реклама чаралары, светофорлар, яктыртыла торган юл билгеләре, мәгълүмати күрсәткечләр.

1.3. Торак йортлар, административ һәм җитештерү бинаалары.

1.4. Бинаалар (аерым торучы, янкорма рәвешендә), вакытлыча җир өсте корылмалары:

- сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары, автосервис, автозаправка станцияләре, ачык автостоянкалар һ.б. (коймаларын да кертеп).

2. Беренче катлардагы бинааларда, корылмаларда урнашкан һәм гомуми файдалanudагы территориягә тышкы чыгу юлы булган торак булмаган бинааларны реконструкцияләү, яңадан җиһазлау, яңадан планлаштыру һәм капиталь ремонтлау.

3. Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү.

4. Планлаштыру эшләре (грунтны кисеп алып, уйсулыкларны һәм чокырларны күмү)

2 кушымта

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе**

___________________________________________

Кемнән:

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

______________ (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

(юридик затлар өчен - тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, дәүләт теркәве турында белешмәләр; физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белешмәләре)

ГАРИЗА

Килештерүегезне һәм объектта җир эшләрен башкаруга ордер бирүегезне сорыйм

___________________________________________________________________________

(объектның исеме, адресы)

Заказчы

____________________________________________________________

(заказчы оешмасының атамасы)

__________________________________________________________________

(башкарыла торган эшләрнең төрләре)

Эшләр түбәндәге срокларда башкарылачак:

«__» ______20__ ел «__» ______20__ елга кадәр

Эшләр башкару өчен җаваплы:

___________________________________________________________________________

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефоны)

«____» ____________20__ ел

__________________________

3 нче кушымта

## Документларның тулы исемлеге

**I. Ордер алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:**

1. Җир һәм төзелеш эшләре, инженерлык челтәрләрен һәм коммуникацияләрне һәм Зәй шәһәрендә тышкы төзекләндерү элементларын бозу белән бәйле эшләрне башкаруга ордер алуга гариза (2 нче кушымта).
2. Шәхесне раслаучы яки ордерны рәсмиләштерүгә юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документлар.
3. 1:1000 һәм 1:500 масштабындагы график материаллар белән проект документлары.
4. Утырган һәм деформацияләнгән очракта, өч ел дәвамында төзекләндерү объектын кабат торгызуга гарантияле йөкләмә (инженерлык коммуникацияләрен авария-торгызу ремонтына бәйле рәвештә җир эшләрен башкаруга ордерга кушымта);
5. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына (мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча) салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә (һәм) авария белән бәйле хәл очраклары өчен белешмә соралмый (билгеләнми).

**II. Инженерлык коммуникацияләрен авариядән соң ремонтлау белән бәйле рәвештә җир эшләре башкаруга ордер рәсмиләштерү өчен түбәндәгеләр тапшырыла:**

- авариядән соң торгызу эшләрен башкару урынынының җентекле адресын, җаваплы башкаручы (мастерның Ф.И.А.) күрсәтеп, җитәкче имзасы белән ордер алу турында хат.

Авария килеп чыгу турында телефонограмма (факсограммалар) җибәрү белән бер үк вакытта, аварияне бетерүче оешма бер тәүлек эчендә Башкарма комитетта авария белән бәйле җир эшләрен башкаруга ордерны рәсмиләштерергә тиеш.

Кичке һәм төнге вакытта, ял һәм бәйрәм көннәрендә, Башкарма комитетта ордерны якындагы эш көнендә рәсмиләштергән очракта, авария белән бәйле җир эшләрен башкарырга рөхсәт ителә;

- җир утыру һәм деформацияләнүләр барлыкка килгән очракта, төзекләндерү объектын өч ел дәвамында кабат торгызуга гарантияле йөкләмә (инженерлык коммуникацияләрен авария-торгызу ремонтына бәйле рәвештә җир эшләрен башкаруга ордерга кушымта);

**III. Ордерны озайту өчен тапшырыла:**

- элек бирелгән ордерның оригиналы;
- яңа чорга эш графигы;
- башкарылган һәм төгәлләнмәгән эшләр күләме күрсәтелгән эш сызымы.

4 кушымта

**Ордер бирүдән баш тарту өчен нигезләр:**

1) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, йә гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

2) Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, тиешле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында таныклый торган дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара соратуга җавабы килү;

3) Элегрәк алынган ордер буенча җир эшләре үткәргәннән соң бозылган урыннарны торгызу буенча йөкләмәләрне үтәмәү;

Җир кишәрлеге дәүләт (муниципаль) милкенә керми.

**Ордерның ябылуы**

Эшләр тәмамланганнан соң эш башкарылган территорияне төзекләндермәү.